## Сөембикә манарасы

Алтын ае зәңгәр күккә тигән,
Иңнәренә салган тарихны.
Казан уртасында, басып тора,
Үзе горур, үзе сагышлы.

*Куш:* Гасырлардан килгән илче,
Сөембикә манарасы.
Халкыбызның мәхәббәте
Һәм йөрәге ярасы.

Бер карасаң битараф та кебек,
Бер карасаң ярсу, газаплы.
Үрсәләнә, әрни, йә шатлана,
Кочагына кысып Казанны.

*кушымта...*